**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ШЕТНЕВО-ТУЛУШСКОГО**
**сельского поселения**
**Рыбно-Слободского**
**муниципального района**
**422644, с.Шетнево-Тулуши**
ул.М.Джалиля, д.18,

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**ЮГАРЫ ЫРГА авыл җирлегенең**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**422644, Шетнево-Тулуш,**
М.Җәлил урамы, 18.

Тел.: (884 361) 27-451, факс: (884 361) 27-451. электронный адресl: **Stul.Rs@tatar.ru**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 14 августы** **Югары Ырга ав** **№ 9**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең 2017 елның 16 ноябрендәге 16 номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга яраклаштыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 1 октябрендәге 1050 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Югары Ырга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, карар бирәм::

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 16 ноябрендәге 11 номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына (2018 елның 28 мартындагы 3 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

программа паспортында:

1.1) 7 юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле 8 юл өстәргә: «халыкны социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин итүнең максатчан күрсәткечләре (Индикаторлары)»:

1.2) 8-10 юлларны 9-11 юллар белән санарга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Югары Ырга авыл җирлегенең Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 йорт; Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Багаутдинов